КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 февраль г.Казань № 95

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 6 октябрь, 952 нче; 2022 ел, 15 гыйнвар, 16 нчы; 2022 ел, 20 июль, 698 нче; 2022 ел, 18 ноябрь, 1231 нче; 2023 ел, 8 июль, 801 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалкан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктның ундүртенче абзацына «мөһер» сүзеннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар (2024 елның 1 июненнән үз көченә керә торган 1 пунктның өченче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин